МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.10.2018 г.Казань № 962

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2017 елның 3 декаберендә теркәлде, № 5019

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан халык мәшгульлеге өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелүче хезмәтләрнең сыйфаты билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында» 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан халык мәшгульлеге өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын расларга.

3. Әлеге Боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары К.А. Таҗетдиновага йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2018 елның 19
октябрендәге 962 номерлы
боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан халык мәшгульлеге өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан халык мәшгульлеге өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан халык мәшгульлеге өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәткәндә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) административ процедураларының һәм административ гамәлләренең стандартын һәм тәртибен билгели, шулай ук аларның срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучы булып Татарстан Республикасы территориясендә халык мәшгульлеге өлкәсендә түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүче социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тора:

- эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә уку һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарга һөнәри ориентация бирүне оештыру;
- эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү;
- хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру;
- социаль һәм мәдәни яраклаштыру һәм интеграцияләү һәм рус теленә өйрәтү максатларында мигрантларны консультацияләү;
- эшкә урнашу, социаль яраклашу мәсьәләләрендә яшьләргә булышлык күрсәтү, балигълык яшенә җитмәгән гражданнарны эшкә урнаштыру;
- иректән мәхрүм ителү рәвешендә җәза үтәү учреждениеләреннән чыгарылган гражданнарга эшкә урнашырга ярдәм итү;
- җиһазландырылган (тәэмин ителгән) эш урыннарына эшкә урнашуда булышлык күрсәтү;
- инвалидларның мәшгульлегенә һәм инвалидларның үзмәшгульлегенә булышлык күрсәткәндә ярдәм итеп торуны оештыру;
- гражданнарга – туры килә торган эш, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү;

- вакансияләр ярминкәләре һәм белем бирүче эш урыннарын оештыру.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза бирүчеләр булып шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәтен алучылар яисә дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә гамәл кылуга вәкаләт бирелгән затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче) тора.

1.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче булып Министрлык тора. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтү Министрлыкның структур бүлекчәләрендәге вазыйфаи затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.4.1. Министрлык урнашкан урын: Казан ш., Волгоград ур., 47, тел. (843) 557-20-01, электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru.

Эш графигы: көн саен, шимбә, якшәмбе һәм эшләми торган бәйрәм көннәреннән тыш, 9.00 сәгатьтән башлап 18.00 сәгатькә кадәр (җомга көннәрендә 16.45 сәгатькә кадәр), 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр төшке ашка тәнәфес ясап.

Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гаризаларны кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән тыш, эш сәгатьләрендә.

Хезмәт күрсәтүдә катнаша торган, әлеге Регламентның 3.1.3 пункты нигезендә Министрлыкның җаваплы структур бүлекчәләре итеп билгеләнгән Министрлыкның структур бүлекчәләренең белешмә телефоннары турында мәгълүмат әлеге Регламентка белешмәлек кушымтада бирелде.

1.4.2. Дәүләт хезмәте турында, шулай ук Министрлык урнашкан урыны һәм аның эш графигы турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Министрлык холлында урнашкан, дәүләт хезмәтләре турында визуаль һәм тестлы мәгълүматларны үз эченә алган, дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала.

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында;

Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки Министрлыкның (843)557-21-13 белешмә телефоны буенча);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә (электрон почта адресы: mtsz@tatar.ru);

1.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү түбәндәгеләр белән җайга салына:

«Коммерциясез оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1996, № 3, 145 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст.,

кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 14, 1652 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Россия Федерациясе Президенты указы (алга таба – 601 номерлы РФ Президенты указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Намуссыз тәэминатчылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрын алып бару тәртибе турында» 2013 елның 25 ноябрендәге 1062 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 48, 6265 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерияләрен раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 45, 6261 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарның (физик затларның) һәм оешмаларның дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне башкаручы оешмалар белән электрон формада үзара хезмәттәшлеген гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 9 июнендәге 516 номерлы карары белән расланган Гражданнарның (физик затларның) һәм оешмаларның дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, федераль законнар нигезендә аерым гавами вәкаләтләрне башкаручы оешмалар белән электрон формада үзара хезмәттәшлеген гамәлгә ашыру кагыйдәләре (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 25, 3803 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммерциясез оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәтләрне башкаручылар реестры турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Социаль юнәлешле коммерциясез оешманы иҗтимагый файдалы хезмәтләрне башкаручы итеп тану турында карар кабул итү кагыйдәләре (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, № 6, 937 ст. кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммерциясез оешмалар – иҗтимагый файдалы хезмәтләрне башкаручылар реестры турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Иҗтимагый файдалы

хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү критерияләре (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Критерияләр) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, № 6, 937 ст. кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 02.11.2010 № 880 карары белән расланган Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында» 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында нигезләмә (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Нигезләмә) («Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» журналы, 2018, № 66, 2150 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы карары (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru, 17.09.2018, «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы», 21.09.2018, № 70, 2300 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасында гражданнарның эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында һөнәри ориентациясен оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014

елның 13 ноябрендәге 625 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы хокукый мәгълүматының рәсми сайты http://pravo.tatarstan.ru, 08.12.2014, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru, 01.10.2015, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы хезмәт базарында эшсез гражданнарның социаль адаптациясе буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 15 сентябрендәге 649 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru, 14.10.2015, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында эшсез гражданнарга психологик ярдәм курсәтү дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 28 сентябрендәге 674 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru, 28.10.2015, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга һәм, һөнәргә укып яки өстәмә һөнәри белем алып, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган яки мәшгульлек хезмәте органнары юлламасы буенча өстәмә һөнәри белем алган гражданнарга, аларны юридик зат, шәхси эшкуар яисә крестьян (фермер) хуҗалыгы сыйфатында дәүләт теркәвенә алганда, бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме, шулай ук тиешле дәүләт теркәвен үтү өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр бирелә торган финанс ярдәме күрсәтүне дә кертеп, эшсез гражданнарның үзләренә шөгыль табуына булышу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2015 елның 21 сентябрендәге 488 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru, 13.08.2015, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Укудан буш вакытларында 14 яшьтән 18 яшькәчә булган балигъ булмаган гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемгә ия булып, беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькәчә булган эшсез гражданнарны Татарстан Республикасында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 30 ноябрендәге 880 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru, 23.12.2015, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында түләүле җәмәгать эшләре уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын

раслау турында» 2016 елның 21 апрелендәге 219 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru, 19.05.2016, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы http://pravo.tatarstan.ru, 10.08.2015, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.6. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – Министрлык тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр шуларга нигезләнеп кертелүче документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында гарызнамә аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 п.). Гаризаның киңәш ителә торган формасы әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.

Башка төр төшенчәләр һәм терминнар 210-ФЗ номерлы федераль законга туры китереп кулланыла.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Халык мәшгульлеге өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясе оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 2 пункты |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы аталышы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы. | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 2 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләргә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмә (алга таба – бәяләмә) бирү яки әлеге Регламентның 4 нче кушымтасына туры китерелгән формада бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәрләмә җибәрү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүченең ихтыяры буенча кәгазьдәге документ формасында да, шулай | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 6 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | ук әлеге Регламент нигезендә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында да бирелергә мөмкин. | |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры | Бәяләмә бирү турында гариза килгән көннән башлап 30 көн эчендә.<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 6 пункты нигезендә Министрлык тарафыннан гарызнамәләр җибәрелгән очракта күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән артыгракка түгел.<br>Күрсәтелгән карарны кабул итү срогын озынайту турында Министрлык мөрәҗәгать итүчегә бәяләмә бирү турында оешмадан гариза килгән көннән башлап 30 көн эчендә хәбәр итә.<br>Бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәрләмә аңа Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләренә кураторлык итүче урынбасары имза салган көннән башлап өч эш көне эчендә оешмага җибәрелә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы Россия Федерациясе законнарында каралмаган | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 9 пункты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 8 пункты |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри | 1. Әлеге Регламентның 1 нче кушымтасына туры китерелгән формада гариза.<br>Гаризада социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелүче хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтү сыйфатын бәяләү критерияләренә туры | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 5, 6 пунктлары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең |

| | | |
|---|---|---|
| булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | килүе нигезләп күрсәтелә:<br>иҗтимагый файдалы хезмәтнең аның эчтәлегенә (күрсәтү күләменә, срокларына, сыйфатына) карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе;<br>иҗтимагый файдалы хезмәтне күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән коммерциясез оешма хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән югары юридик белеме, юридик өлкәдә эш тәҗрибәсе) булуы.<br>иҗтимагый файдалы хезмәтләрне алучыларның аларның күрсәтелү сыйфатыннан канәгать булуы (формалаштыручы коммерциясез оешмалар реестрына кертелү турында гариза тапшырган елга кадәр 2 ел эчендә коммерциясез оешманың аның тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүгә бәйле гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яки) карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек, компетенцияләренә ярашлы рәвештә бүтән органнар тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләрнең булмавы).<br>коммерциясез оешма турында мәгълүматның ачык һәм үтемле булуы.<br>формалаштыручы коммерциясез оешмалар реестрына кертелү турында гариза тапшырган елга кадәр 2 ел эчендә 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча коммерциясез оешманың намуссыз тәэминатчылар реестрында булмавы.<br>Гаризага оешма тарафыннан күрсәтелүче хезмәтләрнең | 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Критерияләр; |

| | | |
|---|---|---|
| | иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү буенча билгеләнгән критерияләргә туры килүен нигезләүче документлар (белешмәләр, сыйфатламалар, эксперт бәяләмәләре, мәнфәгатьле органнар каршындагы иҗтимагый советларның бәяләмәләре һ.б.), шулай ук салымнар һәм җыемнар, Россия Федерациясе законнарында каралган башка мәҗбүри түләүләр буенча әҗәтләрнең булмавын раслаучы документлар теркәлергә мөмкин.<br>2. Гариза вәкаләтле зат тарафыннан тапшырылган очракта, вәкаләтле затлар өчен ышанычнамә күчермәсе.<br>Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.<br>Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Документларның күчермәләре документ биргән органнар һәм (яки) оешмалар тарафыннан таныкланган килеш тапшырыла.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гариза почта аша җибәрелгәндә, аңа теркәлә торган документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланган булырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Әгәр социаль юнәлешле коммерциясез оешма тиешле иҗтимагый файдалы хезмәт буенча социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр реестрына кертелгән булса, оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү буенча билгеләнгән критерияләргә туры килүен нигезләүче өстәмә документларны тапшыру таләп ителми | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле, дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар алына:<br>дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелүче иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмә бирү турында гариза тапшырылганчы кадәр ике ел эчендә коммерциясез оешманың 44-ФЗ номерлы федеральзакон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә намуссыз тәэминатчылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмавы турында (Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе);<br>салымнар һәм җыемнар, Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән зарури түләүләр буенча әҗәтләрнең булмавы турында (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе). | |

| | | |
|---|---|---|
| тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | Мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларны, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелүче иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүен нигезли торган документларны (белешмәләр, сыйфатламалар, эксперт бәяләмәләре, иҗтимагый советларның бәяләмәләре, дипломнарның һәм рәхмәт хатларының күчермәләре, кирәкле бүтән документлар), шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон формада, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Министрлык мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый | |

| | | |
|---|---|---|
| | актларда тапшырылуы күздә тотылмаган, югарыда саналган документларны тапшыруны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнары, дәүләт бюджетныкы булмаган фондлар органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнары, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның ялгыш яки хокукка каршы килә торган гамәлен (гамәл кылмавын) документаль раслаучы фактны (билгеләрне) ачыклаганда, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә | |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча, норматив хокукый актларда каралган очракларда, алар белән килештерү таләп ителә торган һәм бу гамәл дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган дәүләт хакимияте органнарының һәм аларның структур бүлекчәләренең исемлеге | Бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү мәсьәләләренә кураторлык итүче урынбасары тарафыннан имзалана | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Нигезләмәнең 7 пункты |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре юк | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.<br><br>Бәяләмә бирүдән баш тарту нигезләре булып түбәндәгеләр тора: | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләрнең 7 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| исемлеге | 1) иҗтимагый файдалы хезмәтнең аның эчтәлегенә (күрсәтү күләменә, срокларына, сыйфатына) карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;<br>2) иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән оешмаларның хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән югары юридик белеме, юридик өлкәдә эш тәҗрибәсе) булмавы;<br>3) бәяләмә бирелгән елдан элеккеге 2 ел эчендә оешманың аның тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештәге гамәлләренә (гамәл кылмавына һәм (яки) карарларына карата суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләренә туры китереп бүтән дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләрнең булуы;<br>4) оешма турында мәгълүматның ачык һәм үтемле булу дәрәҗәсенең Россия Федерациясе норматив хокукый акларында билгеләнгән таләпләргә (булган очракта) туры килмәве;<br>5) бәяләмә бирелгән елдан элеккеге 2 эчендә «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча оешма турында намуссыз тәэминатчылар реестрында мәгълүмат булуы;<br>6) салымнар һәм җыемнар буенча, Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән мәҗбүри түләүләр буенча | |

| | | |
|---|---|---|
| | әҗәтләр булуы;<br>7) төгәл булмаган белешмәләре булган документларны яки тиешле тәртиптә рәсмиләштерелмәгән документларны тапшыру. | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре, мондый түләү күләмен хисаплау методикасы турында мәгълүматны да кертеп | Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган бүтән хезмәтләрне алу таләп ителми.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып торган хезмәтләрне күрсәткән өчен түләү каралмаган. | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты | Гариза һәм документлар тапшырганда чират көтүнең максималь срогы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү 5 минуттан артып китә алмый. | РФ Президентының № 601 Указының 1 пунктындагы «д» пунктчасы. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гарызнамәсен, шул исәптән электрон рәвештә теркәү вакыты | Гариза Министрлык тарафыннан килгән көнендә теркәлә.<br>Әгәр әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, почта юлламасы белән яки электрон документ (документлар пакеты) рәвешендә җибәрелгән гариза һәм документлар Министрлыкның эш вакыты тәмамлангач килсә, аларны алу көне булып киләсе эш көне санала. Әгәр гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) ял яки бәйрәм көнендә алынса, аларны алу көне булып киләсе эш көне санала.<br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән барлык документлар тапшырылган көн гаризаны тапшыру көне булып санала.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнары нигезендә инвалидлар өчен файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә, дәүләт | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәте күрсәтүнең визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларын урнаштыруга һәм җайлаштыруга карата таләпләр | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы | Министрлык, дәүләт хезмәте күрсәтү срокларын, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүнең Регламентта билгеләнгән тәртибен, үтәү юлы белән, дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын һәм мөмкинлекле булуын тәэмин итә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>биналарның җәмәгатьчелек транспортыннан файдалана алу зонасында урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында тулы мәгълүмат булуы;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче | |

| | | |
|---|---|---|
| турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып | тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Министрлык белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән бәйләнешкә керү саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен алу өчен зарури гариза белән документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлык сайтында http://mtsz.tatarstan.ru, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәтләрнең бердәм порталында, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында http://www.gosuslugi.ru алынырга мөмкин | |
| 2.16. Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә тапшырылырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый. | 63-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 11 пункты;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 21.1 статьясы. |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Административ процедураларның тулы исемлеге

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә;

гаризаны теркәлгән документлар пакеты белән кабул итү һәм теркәү;

коммерциясез оешма тапшырган документлардагы белешмәләрнең тулы һәм төгәл булуын тикшерү;

ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) җибәрү;

документларны карау;

бәяләмә проектын яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә әзерләү турында карар кабул итү;

бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне мөрәҗәгать итүчегә бирү (җибәрү);

техник хатаны төзәтү;

дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәк аша, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша күрсәтү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы әлеге Регламентка 2 нче кушымтада күрсәтелде.

3.1.3. Әлеге Регламентның 3.1.1 пунктының икенче, дүртенче-тугызынчы абзацларында күрсәтелгән административ процедуралар Министрлыкның җаваплы структур бүлекчәләренең вазыйфаи затлары тарафыннан башкарыла:

эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә уку һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарга һөнәри ориентация бирүне оештыру; эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү; хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру; социаль һәм мәдәни яраклаштыру һәм интеграцияләү һәм рус теленә өйрәтү максатларында мигрантларны консультацияләү буенча иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтү турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җаваплы структур бүлекчә булып Министрлыкның һөнәргә укыту һәм һөнәри ориентация бирү бүлеге тора;

эшкә урнашу, социаль тернәкләндерү мәсьәләләрендә яшьләргә булышлык күрсәтү, балигълык яшенә җитмәгән балаларны эшкә урнаштыру; иректән мәхрүм ителү рәвешендә җәза үтәү учреждениеләреннән чыгарылган гражданнарга эшкә урнашырга булышлык күрсәтү; җиһазландырылган (тәэмин ителгән) эш урыннарына эшкә урнашуда булышлык күрсәтү; инвалидларның мәшгульлегенә һәм инвалидларның үзмәшгульлегенә булышлык күрсәткәндә ярдәм итеп торуны оештыру буенча иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җаваплы структур бүлекчә булып Министрлыкның социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары оештыру бүлеге тора;

гражданнарга – туры килә торган эш, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү буенча иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җаваплы структур бүлекчә булып Министрлыкның хезмәт базарын мониторинглау һәм дәүләт хезмәтләре бүлеге тора;

вакансияләр ярминкәләрен һәм белем бирүче эш урыннарын оештыру буенча иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җаваплы структур бүлекчә булып Министрлыкның хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек бүлеге тора.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә

Мөрәҗәгать итүче шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша Министрлыкка дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи заты шәхсән, телефон аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать иткән ысулы нинди булуга карап, мөрәҗәгать итүчене, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен зарури булган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияли һәм мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Административ процедураның нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: консультация, тапшырылган документларның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны төзү өлешендә.

3.3. Гаризаны теркәлгән документлар пакеты белән кабул итү һәм теркәү.

3.3.1. Гаризаны теркәлгән документлар пакеты белән кабул итү һәм теркәү административ процедурасын башлап җибәрү нигезе булып Министрлыкка мөрәҗәгать итүченең әлеге Регламентка 1 нче кушымтага туры китерелгән формада, әлеге Регламентның 2.5 пунктына ярашлы рәвештә документларны (документларның күчермәләрен) теркәп, гариза тапшыруы тора.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән тыш) почтадан, җибәрелү фактын һәм датасын раслау мөмкинлеген бирә торган ысул белән, җибәрелергә мөмкин.

63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә тапшырылырга мөмкин.

3.3.2. Министрлыкта корреспонденцияне теркәү өчен җаваплы булган Министрлыкта эш башкару бүлегенең вазыйфаи заты (алга таба – документларны теркәү өчен җаваплы вазыйфаи зат) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә тапшырылган гаризаның ике нөсхәсендә керү номерын куя, аның берсен мөрәҗәгать итүчегә бирә.

Документларны теркәү өчен җаваплы вазыйфаи зат Министрлыкта билгеләнгән

эш башкару тәртибендә почта аша, электрон саклагычта, яки, «Интернет» челтәрен дә кертеп, уртак файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып килгән гаризаны терки.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза теркәлгән документлар пакеты белән шәхсән тапшырылганда яки гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар килгән көнне;

гариза һәм документлар, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша килгәндә, – гариза һәм документлар Министрлыкка килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Министрлыкның эш сәгате тәмамланган вакытта алынган очракта, аннан соңгы көндә. Гариза һәм документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Министрлыкның ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Административ процедураның нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

Министрлыкта гаризаны теркәү;

мөрәҗәгать итүчегә гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырылганда гаризаны кабул итү фактын раслаучы документны бирү.

3.3.3. Документларны теркәү өчен җаваплы вазыйфаи зат Министрлыкта билгеләнгән эш башкару тәртибендә гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны (документларның күчермәләрен) электрон формада электрон документ әйләнеше системасы аша министрның мәшгульлек мәсьәләләрен тикшерүдә тотучы урынбасарына яки аны алмаштыручы затка (алга таба – министр урынбасары) җибәрә.

3.3.4. Министр урынбасары Министрлыкта билгеләнгән эш башкару тәртибендә гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны (документларның күчермәләрен) электрон формада электрон документ әйләнеше системасы аша әлеге Регламентның 3.1.3 пунктында күрсәтелгән җаваплы структур бүлекчәгә җибәрә.

3.3.5. Җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтү сыйфатына бәяләү уздыру өчен җаваплы структур бүлекчәнең вазыйфаи затын (алга таба – Бүлекнең вазыйфаи заты) билгели (резолюция формасында).

Административ процедураны үтәү срогы: гариза теркәлгән көннән башлап 1 эш көне.

Административ процедураның нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

гаризан һәм аңа теркәлүче документларны (документларның күчермәләрен) эш башкару тәртибен җаваплы структур бүлекчәгә җибәрү;

җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан Бүлекнең вазыйфаи затын билгеләү, электрон документ әйләнеше системасында резолюция рәвешендә рәсмиләштерү.

3.4. Коммерциясез оешма тапшырган документлардагы белешмәләрнең тулы һәм төгәл булуын тикшерү

3.4.1. Административ процедураны гамәлгә ашыру нигезе булып Бүлекнең вазыйфаи заты тарафыннан социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатына бәяләү уздыру өчен теркәлгән документлары (документларның күчермәләре) белән Мөрәҗәгать итүче

тапшырган гаризаның алынуы тора.

3.4.2. Бүлекнең вазыйфаи заты әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерә.

3.4.3. Кирәкле документларның булмау фактлары билгеләнгәндә, әлеге Регламентның 3.7 пунктындагы бишенче абзацта каралган процедура гамәлгә ашырыла.

Административ процедураны үтәү срогы: гаризаны теркәгәннән соң 3 эш көне.

Процедураның нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документлар тупланышының булуы яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә проекты.

3.5. Ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) җибәрү

3.5.1. Административ процедураны гамәлгә ашыру нигезе булып Министрлыкта Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән мәгълүматның (белешмәләрнең) булмавы тора.

3.5.2. Бүлекнең вазыйфаи заты ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәгеләрнең тапшырылуы турында электрон рәвештә белешмәләр (документлар) бирү турында гарызнамәләр җибәрә:

1) социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелүче иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмә бирү турында гариза тапшырылганчы кадәр ике ел эчендә социаль юнәлешле коммерциясез оешманың 44-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә төзелгән контрактларны үтәү кысаларында хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә намуссыз тәэминатчылар (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмавы турында (Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе);

2) салымнар һәм җыемнар, Россия Федерациясе законнарында каралган бүтән зарури түләүләр буенча әҗәтләрнең булмавы турында раслаучы (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе).

Ведомствоара гарызнамә электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешентә формалаштырыла һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы (алга таба – ВЭХС) каналлары буенча җибәрелә.

Ведомствоара электрон гарызнамәне электрон документ рәвешендә формалаштыру һәм ВЭХС каналлары буенча җибәрүнең техник мөмкинлекләре булмаганда, ведомствоара гарызнамә кәгазьдә почта аша, бер үк вакытта почта аша яисә курьер ярдәмендә җиткерү юлы белән факс буенча җибәрелә.

Ведомствоара гарызнамә 210-ФЗ номерлы федераль законның 7.2 статьясы таләпләре нигезендә формалаштырыла.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедураны үтәү срогы: гариза теркәлгән көннән башлап 3 эш көне.

Процедураның нәтиҗәсе: ведомствоара гарызнамә формалаштыру һәм җибәрү.

3.5.3. Ведомствоара хезмәттәшлек органнары белгечләре шушы Регламентның 3.5.2 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән ведомствоара гарызнамәләр нигезендә соралучы белешмәләрне (документларны) законнарда билгеләнгән чорда бирә.

Процедураның нәтиҗәсе: гарызнамәгә җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр

(документлар) яисә соралучы белешмәләрнең булмавы турында Министрлыкка җибәрелгән хәбәрләмә.

3.5.4. Министрлыкка күрсәтү сыйфатына бәяләү Татастан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Нигезләмә кушымтасына ярашлы рәвештә Министрлык һәм Татарстан Республикасының бүтән башкарма хакимият органнары (алга таба – мәнфәгатьле органнар) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган иҗтимагый файдалы хезмәткә кагылышлы гариза килгән очракта, Министрлык зарурлык булганда мәнфәгатьле органнардан, шулай ук дәүләт хакимиятенең башка органнарыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә белешмәләр сората. Ведомствоара гарызнамәгә җавап срогы күрсәтелгән органнарга ведомствоара гарызнамә килгән көннән башлап унбиш эш көненнән артык була алмый.

Административ процедураны үтәү срогы: гариза теркәлгән көннән башлап 15 эш көне.

Процедураның нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: әлеге Регламентның 2.6 пунктында каралган документларның булуы.

3.6. Документларны карау

3.6.1. Административ процедураны уздыру нигезе булып Бүлек вазыйфаи затында әлеге Регламентның 2.5 һәм 2.6 пунктлары нигезендә документлар тупланышының булуы тора.

3.6.2. Күрсәтелгән документларны Бүлекнең вазыйфаи заты тарафыннан карау барышында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

документларны рәсмиләштерүнең дөрес булуы тикшерелә;

социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан гаризада күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфаты әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән критерияләргә туры килүен бәяләү;

социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан гаризада күрсәтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфаты әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән критерияләргә туры килүе (туры килмәве) турында нигезләнгән нәтиҗәләрне үз эченә алган, документаль рәсмиләштерелгән белешмәне (алга таба – коммерциясез оешма хезмәтләренең сыйфаты туры килүе (туры килмәве) турында белешмә) әзерләү.

Административ процедураны үтәү срогы: ведомствоара гарызнамәләргә җавап килгән көннән башлап 1 эш көне.

Административ процедураның нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: коммерциясез оешма хезмәтләренең сыйфаты туры килүе (туры килмәве) турында белешмә.

3.7. Бәяләмә проектын яисә бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә әзерләү турында карар кабул итү.

Документларны карау йомгаклары буенча Бүлекнең вазыйфаи заты бәяләмә бирүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләрнең булуын тикшерүне гамәлгә ашыра.

Бәяләмә бирүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, әлеге Регламентның 2.3 пункты нигезендә бәяләмә проекты әзерли һәм аны килештерү өчен министрга (министр урынбасарына) җибәрә.

Министр (министр урынбасары) тарафыннан килештерелгән бәяләмә проекты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелә.

Бәяләмә бирүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр булган очракта, әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына туры китерелгән формада бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә проектын әзерли һәм аны килештерү өчен министрга (министр урынбасарына) җибәрә.

Министр (министр урынбасары) тарафыннан килештерелгән бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә проекты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелә.

Административ процедураны үтәү срогы: ведомствоара гарызнамәләргә җавап килгән көннән башлап 2 эш көне, ләкин әлеге Регламентта билгеләнгән бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә) бирү срогы тәмамланырга кимендә 10 көн калганчы.

Административ процедураның нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә проекты.

3.8. Бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне мөрәҗәгать итүчегә бирү (җибәрү)

3.8.1. Мөрәҗәгать итүчегә документлар бирү (җибәрү) нигезе булып Бүлекнең вазыйфаи затына Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләрен тикшерүдә тотучы урынбасары тарафыннан имзаланган бәяләмәнең яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәнең килүе тора.

3.8.2. Бүлекнең вазыйфаи заты әлеге Регламентның 3.8.1 пунктында күрсәтелгән документларны алган көннән башлап 1 эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (язмача, электрон почта аша) бәяләмәнең (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәнең) әзер булуы турында хәбәр итә.

Гаризада бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) почта аша ысулы күрсәтелгәндә, хәбәрләмә җибәрелми.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бәяләмәнең (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәнең) әзер булуы турында хәбәр итү.

3.8.3. Бүлекнең вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (шәхсән, почта аша) имзаланган бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

гаризада бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) почта аша тапшыру турында күрсәтелгәндә - Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләрен тикшерүдә тотучы урынбасары тарафыннан имзаланган бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә килгән көненнән башлап ике эш көне эчендә;

гаризада бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) шәхсән бирелүе турында күрсәтелгәндә – мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, Бүлекнең вазыйфаи заты

шәхес таныклаучы документны тикшерү юлы белән мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәге тора:бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә) бирү (җибәрү).

3.9. Техник хатаны төзәтү.

Бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне үзгәртеп рәсмиләштерү элегрәк бирелгән бәяләмәдә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәдә җибәрелгән техник хаталарны (язу, басма хаталарны, грамматик яки арифметик хаталарны) бетерүгә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла.

Бәяләмәне яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне үзгәртеп рәсмиләштерү әлеге Регламентка 4 нче кушымтага туры китерелгән формада төзелгән гариза (алга таба – мөрәҗәгать) нигезендә гамәлгә ашырыла, ул мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкка турыдан-туры тапшырыла яки почта юлламасы итеп теркәлгәннәр исемлеге белән яки электрон имза белән имзаланган электрон документ (гарызнамә) формасында җибәрелә, шул исәптән, «Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын, «Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасын да кертеп.

3.9.1. Документларны теркәү өчен җаваплы вазыйфаи зат түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгатьне кабул итә һәм терки;

мөрәҗәгатьне электрон документ әйләнеше аша электрон формада министрга (министр урынбасарына) җибәрә.

3.9.2. Министр (министр урынбасары) мөрәҗәгатьне карый һәм карау өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесенә җибәрә.

3.9.3. Җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе техник хатаны төзәтү өчен җаваплы структур бүлекчәнең вазыйфаи затын (алга таба – техник хатаны төзәтү өчен җаваплы вазыйфаи зат) билгели.

Техник хатаны төзәтү өчен җаваплы вазыйфаи зат түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

техник хатаны төзәтә һәм әлеге Регламентка 3 нче кушымтага туры китерелгән формада бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә проектын әзерли;

үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) килештерү өчен министрга (министр урынбасарына) җибәрә.

Министр (министр урынбасары) тарафыннан килештерелгән бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә) проекты Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар техник хатаны төзәтү турында гариза теркәлгән көннән башлап өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәрләмә.

3.9.4. Бәяләмәгә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәгә)

Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләренә кураторлык итүче урынбасары кул куйганнан соң, техник хатаны төзәтү өчен җаваплы вазыйфаи зат мөрәҗәгать итүчегә техник хатаны төзәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (язмача, электрон почта аша) бәяләмәнең (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәнең) әзер булуы турында хәбәр җиткерә.

Техник хатаны төзәтү турында гаризада бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) почта аша ысулы күрсәтелгәндә, хәбәрләмә җибәрелми.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләренә кураторлык итүче урынбасары кул куйган бәяләмә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә) техник хатаны төзәтү өчен җаваплы вазыйфаи затка килгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәнең (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәнең) әзер булуы турында хәбәр итү.

3.9.5. Техник хатаны төзәтү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турында гаризада күрсәтелгән ысул белән (шәхсән, почта аша) имзаланган бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

техник хатаны төзәтү турында гаризада бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) бирү ысулы почта аша күрсәтелгән очракта – бәяләмәгә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәгә) Татарстан Республикасы Премьер-министрының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар белән үзара хезмәттәшлек мәсьәләләренә кураторлык итүче урынбасары кул куйган көннән соң ике эш көне эчендә;

техник хатаны төзәтү турында гаризада бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) шәхсән бирелүе турында күрсәтелгәндә – мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне.

Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, техник хатаны төзәтү өчен җаваплы вазыйфаи зат шәхес таныклаучы документны тикшерү юлы белән мөрәҗәгать итүченең шәхесен билгели.

Процедураның нәтиҗәсе: бирелгән (җибәрелгән) үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмә яки бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезле хәбәрләмә.

3.10. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәк аша һәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша күрсәтелми.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан Регламентның нигезләмәләре һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүгә таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларның үтәлүен һәм башкарылуын, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы тикшереп тору эше тиешле

административ процедураны башкару өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе һәм министр урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору тикшерүләр уздыруны, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне карауны, алар буенча карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын тикшерүдә тоту Министрлыкның әлеге контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле, вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәләре турында нигезләмәдә һәм вазыйфаи регламентларда билгеләнә торган вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.2. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы булган, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.3. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелүне контрольлектә тоту дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Министрлык эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи зат (хезмәткәр) яисә дәүләт хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның вазифаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәрге тәртиптә Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү сәбәпле министр (министр урынбасары) тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү чоры бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү буенча тапшырылырга тиешле, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

10) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.

5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының, министрның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почтадан, «Интернет» челтәреннән файдаланып күпфункцияле үзәктән, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьләрне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң 15 эш көне эчендә һәм Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр

кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителә торган Министрлыкның, Министрлыкның вазифаи затының яисә дәүләт гражданлык хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче шуларга нигезләнеп, Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять ителә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән риза булмаган дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында Министрлыкта гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан халык мәшгульлеге өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

формасы

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына

(кемнән) ______________________________________________
______________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең тулы аталышы (юридик затлар өчен) Ф.И.А. (физик затлар өчен);ОГРН

______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
урнашкан урыны адресы, телефон (факс), электрон почта адресы һәм мөрәҗәгать итүче белән үзара бәйләнешкә керү мөмкинлеген бирүче бүтән реквизитлар

## Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында гариза

1. «Коммерциясез оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законның 31.4 статьясы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында» 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары нигезендә, халык мәшгульлеге өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмә бирүне сорыйм, түбәндәгегә карата:
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________

*(социаль юнәлешле коммерциясез оешманың тулы аталышы, ИНН, төп дәүләт теркәвенә алу номеры, шулай ук даими эшләүче башкарма органының (даими эшләүче башкарма органы булмаган очракта - аның исеменнән ышанычнамәдән башка эш йөртү хокукына ия булган башка органның яки затның) әлеге оешма белән элемтә гамәлгә ашырыла торган адресы (урнашкан урыны))*

Оешма ________________________________________________________________

*(оешманың аталышы)*

Россия Федерациясе субъектларының яртысыннан артыгы территориясендә бер иҗтимагый файдалы хезмәтне күрсәтүче һәм (яки) иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүенә бәйле рәвештә федераль бюджет акчалары хисабыннан финанс ярдәмен алучы

________________________________________________________________ оешма.

*(булып тора / булып тормый)*

Раслыйбыз, оешма

________________________________________________________________

*(оешманың аталышы)*

чит ил агенты функцияләрен башкаручы коммерциясез оешма булып тормый һәм бер ел һәм аннан күбрәк чорда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерияләрен раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карарында расланган иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү критерияләренә туры килүче атап үтелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтә:

2. Мөрәҗәгать итүче күрсәтә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр турында белешмәләр <*>

________________________________________________________________

________________________________________________________________

________________________________________________________________

*(Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеген һәм аларны күрсәтү сыйфатын бәяләү критерияләрен раслау турында» 2016 елның 27 октябрендәге 1096 номерлы карары белән расланган иҗтимагый файдалы хезмәтләр исемлеге нигезендә халык мәшгульлеге өлкәсендә иҗтимагый файдалы хезмәтнең исеме)*

*эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә уку һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарга һөнәри ориентация бирүне оештыру;*

*эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү;*

*хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль яраклаштыру;*

*социаль һәм мәдәни яраклаштыру һәм интеграцияләү максатларында мигрантларны консультацияләү;*

*эшкә урнашу, социаль яраклашу мәсьәләләрендә яшьләргә булышлык күрсәтү, балигълык яшенә җитмәгән гражданнарны эшкә урнаштыру;*

*иректән мәхрүм ителү рәвешендә җәза үтәүче учреждениеләрдән чыгарылган гражданнарга эшкә урнашырга ярдәм итү;*

*җиһазландырылган (тәэмин ителгән) эш урыннарына эшкә урнашуда булышлык күрсәтү;*

*инвалидларның мәшгульлегенә һәм инвалидларның үзмәшгульлегенә булышлык күрсәткәндә ярдәм итеп торуны оештыру,*

*гражданнарга – туры килә торган эш, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлап алуда булышлык күрсәтү, вакансияләр ярминкәләре һәм белем бирүче эш урыннарын оештыру)*

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтү сыйфатын бәяләү критерияләренә туры килүен нигезләү

| | |
|---|---|
| 1. Иҗтимагый файдалы хезмәтнең анык эчтәлегенә (күрсәтү күләменә, срокларына, сыйфатына) карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат).<br>2. Иҗтимагый файдалы хезмәтне күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы затларның (шул исәптән коммерциясез оешма хезмәткәрләренең һәм граждани-хокукый холыклы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең) кирәкле квалификациясе (шул исәптән югары юридик белеме, юридик өлкәдә эш тәҗрибәсе) булуы турында мәгълүмат. | |
| 3. Иҗтимагый файдалы хезмәтләрне алучыларның аларны күрсәтүдән канәгать булуы (социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган халык мәшгульлеге өлкәсендә иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмә бирү турында гариза тапшырганчыга кадәр ике ел эчендә иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүгә бәйле рәвештә, оешманың гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм (яки) карарларына суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, компетенцияләренә туры китереп, бүтән дәүләт органнары тарафыннан нигезле дип танылган шикаятьләрнең булуы яки булмавы турында белешмәләр, тиешле суд, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль күзәтчелек органнары, бүтән дәүләт органнары карарларының реквизитларын күрсәтеп) | |

3. «Интернет» челтәрендә социаль юнәлешле коммерциясез оешманың рәсми сайт адресы ______________________________________________________________

4. Бәяләмәнең (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәнең) әзер булуы турында хәбәрне түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

___________________________________________________________________________

*(язмача (адрес күрсәтергә), электрон почта аша (адрес күрсәтергә))*

5. Гаризаны карау нәтиҗәләре буенча хәбәрләмәне түбәндәгечә бирүне сорыйм: ____________________

*(шәхсән, почта аша)*

**Дәлилләүче документлар теркәлә:

1.
2.
3.

_________________________________________ «__» __________ 20 __ ел.

(оешма исеменнән ышанычнамәдән башка эш йөртү хокукына ия булган вазыйфаи затның имзасы, Ф.И.А.)


--------------------------------

<*> Әлеге гариза пунктындагы пунктчалар саны үзләренә карата гариза тапшырылган иҗтимагый файдалы хезмәтләр саны белән туры килергә тиеш.

<**> Гаризага социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең халык мәшгульлеге өлкәсендә иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча билгеләнгән критерияләргә туры килүен нигезли торган, гариза бирүченең үз ихтыяры белән тапшырыла торган документлар (белешмәләр, сыйфатламалар, эксперт бәяләмәләре, мәнфәгатьле органнар каршысындагы иҗтимагый советларның бәяләмәләре һ.б.) теркәлергә мөмкин.

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан халык мәшгульлеге өлкәсендә күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең сыйфаты туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

# ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕН КҮРСӘТКӘНДӘ ГАМӘЛЛӘРНЕҢ ЭЗЛЕКЛЕЛЕГЕ БУЕНЧА БЛОК-СХЕМА



**Техник хатаны төзәтүгә гаризаны кабул итү һәм теркәү**

↓

**Халык мәшгульлеге өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) үзгәртеп рәсмиләштерү һәм бирү;**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентына 3 нче кушымта

формасы

Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмә

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан уздырылган иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтүнең сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча түбәндәге социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан:

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(социаль юнәлешле коммерциясез оешманың тулы аталышы һәм төп дәүләт теркәвенә алыну номеры)

күрсәтелә торган түбәндәге иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең:

_________________________________________________________________________;

_________________________________________________________________________;

_________________________________________________________________________.

(иҗтимагый файдалы хезмәтләрнең исеме)

сыйфаты иҗтимагый файдалы хезмәтләрне күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмә бирүдән баш тарта, түбәндәге нигезләр буенча:

_________________________________________________________________________;

_________________________________________________________________________;

_________________________________________________________________________.

____________/____________(Ф.И.А., вазыйфа)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентына 4 нче кушымта

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына

формасы

Техник хата төзәтү турында гариза

______________________________________________________________________

*(оешманың тулы аталышы, ИНН, төп дәүләт теркәвенә алу номеры, шулай ук даими эшләүче башкарма органының (даими эшләүче башкарма органы булмаган очракта - аның исеменнән ышанычнамәдән башка эш йөртү хокукына ия булган башка органның яки затның) әлеге оешма белән элемтә гамәлгә ашырыла торган адресы (урнашкан урыны) )*

техник хатаны төзәтүне сорый _____________________________________________
__________________________________________________________________,
__________________ № ________________ социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый файдалы хезмәтләр сыйфатының билгеләнгән критерияләргә туры килүе турында бәяләмәдә (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәдә) җибәрелгән.
*(карар датасы карар номеры)*

Гаризаны карау нәтиҗәләре буенча хәбәрләмәне түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

______________________________________________________________________

*(язмача (адрес күрсәтергә), электрон почта аша (адрес күрсәтергә))*

Гаризаны карау нәтиҗәләре буенча үзгәртеп рәсмиләштерелгән бәяләмәне (бәяләмә бирүдән баш тарту турында нигезләнгән хәбәрләмәне) түбәндәгечә бирүне сорыйм:

______________________________________________________________________

*(шәхсән, почта аша)*

«__» ___________ 20__ел. _______________________ __________________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)

«__» ___________ 20__ел. ________________________ __________________________________
(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентына (белешмәлек) кушымта

# ХАЛЫК МӘШГУЛЬЛЕГЕ ӨЛКӘСЕНДӘ СОЦИАЛЬ ЮНӘЛЕШЛЕ КОММЕРЦИЯСЕ ОЕШМА ТАРАФЫННАН ИҖТИМАГЫЙ ФАЙДАЛЫ ХЕЗМӘТЛӘР КҮРСӘТҮНЕҢ СЫЙФАТЫН БӘЯЛӘҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮ БУЕНЧА ҖАВАПЛЫ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРНЫҢ РЕКВИЗИТЛАРЫ

**Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы**

| Вазыйфасы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының структур бүлекчәсе аталышы | Телефоны | электрон адресы |
|---|---|---|---|
| Министр | | (843) 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | | (843) 557-20-03 | Klara.Tazetdinova@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | һөнәргә укыту һәм һөнәри юнәлеш бирү бүлеге | (843) 557-20-90 | Sofya.Tonkonog@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | социаль якланмаган категорияләр өчен эш урыннары оештыру бүлеге | (843) 557-20-93 | Irina.Posokova@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | хезмәт базарын мониторинглау һәм дәүләт хезмәтләре бүлеге | (843) 557-20-73 | Elena.Kibardina@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | хезмәт миграциясе һәм эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлек итү бүлеге | (843) 557-21-58 | Azat.Ayupov@tatar.ru |
| Бүлек башлыгы | эш башкару бүлеге | (843) 557-21-01 | Svetlana.Novikova@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты**

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы | (843) 264-77-29 | pisma@tatar.ru |